| | |
|---|---|
| СОВЕТ КУГУШЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КҮГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**03 июнь 2024 ел** Күгеш авылы **№178**

Күгеш авыл җирлеге Советының 2017 елның 29 ноябрендәге 121 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (Күгеш авыл җирлеге Советының 2018 елның 26 апрелендәге 137 номерлы, 2019 елның 15 февралендәге 184 номерлы, 2020 елның 04 августындагы 249 номерлы, 2021 елның 19 декабрендәге 44 номерлы, 2022 елның 19 декабрендәге 102 номерлы, 2023 елның 16 гыйнварындагы 113 номерлы, 2023 елның 09 февралендәге 117 номерлы, 2023 елның 19 апрелендәге 128 номерлы, 2023 елның 18 июлендәге 138 номерлы, 2023 елның 29 августындагы 143 номерлы, 2024 елның 07 маендагы 172 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларын, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларын, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләрен, Рәис урынбасарларын, аудиторларын һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладларын айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турындагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында"карары нигезендә Совет Күгеш авыл җирлеге карар **кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге Советының 2017 елның 29 ноябрендәге 121 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районының «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (Күгеш авыл җирлеге Советының 2018 елның 26 апрелендәге 137 номерлы, 2019 елның 15 февралендәге 184 номерлы, 2020 елның 04 августындагы 249 номерлы, 2021 елның 05 июлендәге 44 номерлы, 2022 елның 19 декабрендәге 102 номерлы, 2023

елның 16 гыйнварындагы 113 номерлы, 2023 елның 09 февралендәге 117 номерлы, 2023 елның 19 апрелендәге 128 номерлы, 2023 елның 18 июлендәге 138 номерлы, 2023 елның 29 августындагы 143 номерлы, 2024 елның 07 маендагы 172 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертергә:

1.1. 23 нче маддәдә:

23.9 пунктта «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләре белән алыштырырга;

23.15 пунктның 6 нчы пунктчасында «унсигез процент» сүзен «41 процент»сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә һәм Күгеш авылы, Мәктәп яны урамы, 1а йорт (администрация бинасы) адресы буенча урнашкан торак пунктның мәгълүмати стендында урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

**Күгеш авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе:** **А. А. Гатауллин**